КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 октябрь г.Казань № 850

«Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау белән кызыксынган физик затларга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган федераль бюджет акчалары булган субсидияләр бирү тәртибен һәм «Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау белән кызыксынган физик затларга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс

белән тәэмин итү максатларында  финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган федераль бюджет акчалары булган субсидияләр бирү тәртибе;

«Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин